Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шомырбаш авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 2**

Шомырбаш авылы 2020 елның 4 нче феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 09 октябряндәге "Җир салымы турында"9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, 2019 елның 29 сентябрендәге "Россия Федерацисе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында" 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбыш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге Советының "Җир салымы турында" карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 05 ноябрендәге 10 номерлы ,2015 елның 25 маендәге 11-А номерлы, 2017 елның 28 августадәге 11 номерлы, 2019 елның июндәге 8 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән гайре) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып

алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән гайре) җир кишәрлекләренә карата -0,3%”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш җирлегенең Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авылы, Совет урамы, 47 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Таулар авылы, Ленин урамы, 50А йорты; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Алан Полян авылы, Я.Емельянов урамы, 6 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Кызыл-Йолдыз урманчылыгы, Парк урамы, 10 йорт; адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шомырбаш авыл җирлеге Башлыгы: И.Н.Сафин